УДК 811.512.145’367

***Л.Г. Хәбибуллина***

# ТӨРКИ ТЕЛЛӘРДӘ ШАРТ МӨНӘСӘБӘТЕНЕҢ БИРЕЛЕШЕ
## (Халык авыз иҗаты әсәрләре материалында)

В результате исследования языка произведений народного творчества выявляются особенности мировоззрения того или иного народа. В данной статье изучаются кондициональные отношения на материале примеров из малых жанров тюркского фольклора. Исследование структурно-семантической организации паремиологических конструкций со значением условия представляет интерес в плане выявления средств формального выражения кондициональности.

**Ключевые слова:** кондициональность, условные отношения, кондиционально-темпоральная семантика, тюркский фольклор.

As a result of the study of the language of works of folk art, the features of the worldview of a particular people are revealed. This article studies conditional relations based on examples from small genres of Turkic folklore. The study of the structural and semantic organization of paremiological constructions with the meaning of the condition is of interest in terms of identifying the means of formal expression of conditionality.

**Keywords:** conditionality, conditional relations, conditional-temporal semantics, Turkic folklore.

Шарт категориясе – лингвистика гына түгел, ә тел һәм кешенең сөйләм эшчәнлеген төрле позиция һәм максатларда тикшерә торган фәннәр – психология, логика һәм фәлсәфә тарафыннан актив өйрәнелүче тел объекты. Фәлсәфә дә, логика фәне дә аны берсенең булуы икенчесенең булу-булмавы белән турыдан-туры бәйле ике компоненттан торган катлаулы күренеш буларак өйрәнә. Шарт конструкцияләрендә кеше аңының фаразлау, ниндидер мәгълүматка таянган нәтиҗәләр ясау сәләте белдерелә. «…Хәзерге лингвофольклористика когнитив лингвистика, лингвокультурология, лингвоконцептология, текст теориясе, герменевтика, сөйләм коммуникациясе теориясе белән иң тыгыз рәвештә бәйләнгән» [Сердюк, 2009, с. 43] булганга, мәгънәви мөнәсәбәтләрнең семантикасын һәм белдерелүен фольклор әсәрләре материалында өйрәнү максатка ярашлы дип күзаллана.

Шарт мөнәсәбәте сынамыш һәм ышануларның нигезен тәшкил итә, ягъни алар (сынамыш һәм ышанулар) шарт мөнәсәбәтенә карыла. Мондый паремияләрдә кушма җөмләнең баш җөмләсенең хәбәре, кагыйдә буларак, инфинитив белән белдерелә. Мәсәлән: тат. *Салават күпере төньягында чыкса, яңгыр булмаска* (Сынамыш); *Ай чалкан туса, көннәр аязырга* (Сынамыш); *Болыт кыйблага таба барса, көн аязырга* (Сынамыш).

Кайбер тикшеренүчеләр фикеренчә, «шартлылык сәбәплелекнең нигез катламы булып тора, чөнки әлеге мәгънә мөнәсәбәтләре модаль мәгънә белән тыгыз бәйләнгән» [Свеклова, 2010, с. 220]. Татар һәм башка төрки телләрдә шарт һәм сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләре синкретиклыгы күзәтелә. Мәсәлән, төрки телләрдә шарт мәгънәсе фигыльнең юклык формасы *-ма/-мә* ярдәмендә белдерелә ала. Мондый мисаллар паремияләрдә бик еш очрый, әмма аларда, безнең күзәтүләр буенча, шарт мәгънәсеннән тыш, сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтен дә күзалларга була: тат. *Гаепсез дус эзләмә, ялгыз калырсың* (Әйтем); *Кешене каргама, үзеңә төшәр* (Әйтем); *Гайбәт сөйләмә, бәла ирешмәс* (Әйтем).

Беренчедән, мондый мисалларда шарт мөнәсәбәте бар, фигыльнең юклык формасы кушымчасын шарт наклонениесе аффиксы белән алыштырганда, җөмләнең гомуми семантикасы үзгәрми: *Гаепсез дус эзләсәң, ялгыз калырсың; Кешене каргасаң, үзеңә төшәр; Гайбәт сөйләсәң, бәла ирешер.*

Икенчедән, әлеге паремия компонентлары арасында сәбәп-нәтиҗә бәйлелеге бар: гаепсез дус эзләргә кирәкми, чөнки нәтиҗәдә ялгыз калуың бар; кешене каргарга ярамый, чөнки үзеңә төшә; гайбәт сөйләргә ярамый, чөнки гайбәт – бәлагә. Теркәгечсез конструкцияне теркәгечлегә синтаксик трансформацияләү җөмләнең гомуми логик мәгънәсен һәм структурасын бозмый: *Гаепсез дус эзләмә, чөнки ялгыз калырсың; Кешене каргама, чөнки үзеңә төшәр; Гайбәт сөйләмә, чөнки (гайбәт сөйләсәң) бәла ирешер.*

*-са/-сә* шарт формасы сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләрен белдерүче конструкцияләрдә кулланыла ала. Мисалларны анализлаудан күренгәнчә, еш кына шарт наклонениесе формасы белән, сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтен белдереп, башка чаралар да кулланыла. Мәсәлән: тат. *Битең кызыша, димәк, сине яманлыйлар* (Ышану); *Колагың чыңласа, димәк, сине сөйлиләр* (Ышану).

Күргәнебезчә, югарыда китерелгән җөмләләрдә, нәтиҗә мәгънәсен ассызыклап, *димәк* сүзе кулланылган. Аны төшереп калдырырга да була. Әмма логик яктан шарт наклонениесенең формаль күрсәткече (*-са/-сә* аффиксы) әлеге очракта реаль шартны белдерә алмый, чөнки битеңнең кызышуы – сине яманлауның, колагыңның чыңлавы синең хакта сөйләүнең шарты була алмый.

*Димәк* сүзе күренешне реаль факт итеп белдерүче шарт җөмләдә кулланыла. *Димәк* сүзе җөмләгә яңа семантик төсмер кертә: иярчен компонентта әйтелгән сәбәп нигезендә ясалучы нәтиҗә мәгънәсе ассызыклана. Кайбер җөмләләрдә эксплицит белдерелмәгән шарт мәгънәсе дә, сәбәп-нәтиҗә мәгънәсе дә була. Мәсәлән: тат. *Бер эшкә алындың – бар эшкә алындың* (Мәкаль). Әлеге мисалда сәбәп-нәтиҗә һәм шарт мөнәсәбәтен белдерүче нинди дә булса формаль күрсәткечләр юк. Җөмләне ике төрле аңларга була: *Бер эшкә алынсаң – бар эшкә алынасың* һәм *Бер эшкә алындың – димәк, бар эшкә алындың.*

Төрки телләрдә шарт һәм вакыт мөнәсәбәтләре синкретизмы киң таралган. Паремияләр һәм гомумиләштерелгән әйтелмәләрдә шарт конструкциясе компонентлары мөнәсәбәтләренең абстракт вакыт характеры күзәтелә. Мәсәлән: алт. *Ат киштезе, таныжар, кижи эрмектешсе, таныжар* (Мәкаль); кар. *Басмаса ат айакны, тартарс арабаны* (Мәкаль); карач.-балк. *Агъач чирисе езегинден чирийди* (Мәкаль); *Джангур джауса джерге джауар* (Мәкаль); ком. *Айрылгъан эл азар, къошулгъан эл озар* (Мәкаль); кырг. *Жылуу сөйлөсө, жылан ийинден чыгат* (Мәкаль).

Мисалларны анализлаудан күренгәнчә, паремияләр вакыттан тыш характерга ия, гомуми закончалыкка күрсәтә, типик күренешләргә ишарәли.

Паремияләрдә үткән заман формасының бик сирәк кулланылуы үткән заман формаларының, кагыйдә буларак, чынбарлык белән бәйле булуы, индивидуальләштерү үзлегенә ия булуы белән аңлатыла, ә паремияләргә гомумиләштерү хас. Үткән заман формалы паремияләр еш очрамый. Мәсәлән: ком. *Яшыртгъын айтдым – билмединг, герюне айтдым – сюймединг* (Әйтем).

Шарт-вакыт мөнәсәбәтен белдергән конструкцияләрдә, кагыйдә буларак, альтернатив оппозиция нейтральләшә. Бу бигрәк тә субъектив фикерне белдергән әйтелмәләргә кагыла. Мәсәлән: тат. *Кешене батырсалар, ул саламга да ябыша* (Әйтем).

Кушма җөмләнең хәбәрләре билгеле бер вакытка кагылышы булмаган яки вакытка бәйле булмаган, даими вакыйганы белдергәндә, вакыт мөнәсәбәтенең шарт мөнәсәбәте белән катлаулануы күзәтелә. Мондый конструкцияләрдә еш кына вакыт мәгънәсен белдергән теркәгечләр дә кулланыла, иярчен җөмлә гомумиләшкән мәгънәгә ия була. Мәсәлән: гаг. *Ачан бирлик йок достларда, ишлӓр гитмӓз хич орада* (Мәкаль).

Шарт мәгънәсе урын-вакыт килеше формасындагы хәбәрлек сүзләр ярдәмендә белдерелә ала. Мәсәлән: тат. *Югарыда урын барда, түбән утырма* (Мәкаль).

Шарт мөнәсәбәтен белдерүдә әлеге чара продуктив түгел, мондый конструкцияләрдә ачык булмаган вакыт мәгънәсе дә күзәтелә.

Сирәк очракларда шарт мәгънәсен сыйфат фигыль формасы да белдерә ала. Мәсәлән: башк. *Буренән курккан – урманға бармаған* (Мәкаль); карач.-балк. *Жаз ойнагъан къыш жиляр* (Мәкаль); ком. *Заманны зая этген оьзюн де зая этер* (Мәкаль); *Талап этген – муратгъа етген* (Мәкаль); *Язда ишлемеген къышда тишлемес* (Мәкаль); кырг. *Карышкырдан корккон токойга барбайт* (Мәкаль); *Шашкан – ашка бышкан* (Мәкаль); *Кош коенду кууган куру калат* (Мәкаль); тат. *Иҗтиһат иткән – морадына җиткән* (Мәкаль).

Мисалларны анализлаудан күренгәнчә, сыйфат фигыль формасы белән белдерелгән шарт семантикасына ачык белдерелү хас түгел. Тат. *Кулында китап булганның башында гыйлем булыр* (Әйтем); *Сүз хикмәтен белмәгән кешенең михнәте күп* (Мәкаль); *Башына төшкән*

*башмакчы булыр* (Мәкаль) тибындагы җөмләләрне ике төрле аңлап була: *Кулында китап булса, башында гыйлем булыр; Кеше сүз хикмәтен белмәсә, михнәте күп; Башына төшсә, башмакчы булыр*. Яки: *Кулында китап булганлыктан, башында гыйлем булыр; Сүз хикмәтен белмәгәнлектән, кешенең михнәте күп; Башына төшкәнлектән, башмакчы булыр.*

Урын-вакыт килешендәге *-ган* формалы сыйфат фигыль гадәттә вакыт мөнәсәбәтен белдерүдә кулланыла. Әмма төрки телләрдә *-ганда/-гәндә (-канда/-кәндә)* формасы ярдәмендә бәйләнгән сүзләр арасында кайвакыт шарт семантикасы да урнаша. Шулай итеп, мондый җөмләләрдә вакыт мәгънәсе төсмерле шарт семантикасы белдерелә. Мәсәлән: тат. *Әйткәндә сүзеңчә эшлә, әйтмәгәндә уеңча эшлә* (Мәкаль); *Гыйлем булмаганда, бар акыл да юк була* (Мәкаль).

Шушы ук мәгънәне *-ган очракта* формасы белән дә белдереп була. Мәсәлән: *Әйткән очракта сүзеңчә эшлә, әйтмәгән очракта уеңча эшлә; Гыйлем булмаган очракта, бар акыл да юк була.*

Күргәнебезчә, *-ганда* формасы ярдәмендә вакыт һәм шарт мәгънәләре киселешендәге мөнәсәбәтләр белдерелә. Шуны да әйтергә кирәк: бу очракта шарт мәгънәсе кабатлана торган, һәрвакыт була торган күренешләр турында хәбәр итә. *-ганда* формасын *-са* формасына алыштырганда, компонентлар эчтәлеге арасындагы вакытка мөнәсәбәт югала. Мәсәлән: тат. *Гаиләдә татулык булганда, эшләр уңай бара* (Әйтем). → *Гаиләдә татулык булса, эшләр уңай бара.*

Мәгълүм булганча, теркәгечсез конструкцияләр күптөрле мәгънәви мөнәсәбәтләрне белдерә ала. Шарт мөнәсәбәтләрен анализлаганда, аларның теркәгечсез кушма җөмләләр ярдәмендә белдерелүе еш кына тикшеренүчеләр күзлегеннән читтә кала. Әмма мондый конструкция компонентлары арасында теге яки бу семантиканың формаль күрсәткечләре белән белдерелмәгән шарт мөнәсәбәте урнаша ала. Бу очракта мәгънәви мөнәсәбәт җөмләнең эчтәлегеннән чыгып билгеләнә. Мондый мисаллар, кагыйдә буларак, эчтәлеге гомумиләшкән характерга ия мәкаль һәм әйтемнәрдә очрый. Мисаллар китерик: азәрб. *Инәк су ичәр, сүд олар. Илан су ичәр, зәһәр олар* (Мәкаль); *Ай доғар күн динчәләр* (Мәкаль); гаг. *Дам чӧкäр дирек истäр, кар йаар кӱрек истäр* (Мәкаль); төр. *At ölür nalı kalır, adam ölür namı kalır* (Мәкаль); үзб. *Қўшнинг тинч – сен тинч* (Мәкаль). Мондый теркәгечсез кушма җөмләләрдә шарт һәм вакыт мәгънәләренең керешүе күзәтелә.

Мисалларны анализлаудан күренгәнчә, төрки телләрдә шарт мөнәсәбәте эксплицит һәм имплицит рәвешләрдә дә, белдерелә ала. Тикшеренү барышында берничә мәгънәви мөнәсәбәт киселешендә торган конструкцияләр дә ачыкланды.

Шулай итеп, фольклорның кече жанрлары, аеруча паремияләр, – катлаулы логик система. Аларның семантик структурасында ‘шарт’ төшенчәсе аерым урын алып тора, еш кына нигезләрен тәшкил итә.

**Әдәбият**

*Свеклова О.В.* Синонимия в условных смысловых отношениях (на материале русского и чувашского языков) // Вестник Чувашского университета. 2010. № 4. С. 220–223.

*Сердюк М.А.* Актуальные проблемы изучения фольклорных текстов // Вестник Тамбовского университета. Серия: Гуманитарные науки. 2009. № 2 (70). С. 42–45.

*Татар грамматикасы:* өч томда / проект җит. һәм автор М.З. Зәкиев. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2017. III т. 536 б.

**Кыскартылмалар**

Азәрб. – азәрбайҗан.
Алт. – алтай.
Башк. – башкорт.
Гаг. – гагауз.
Кар. – караим.
Карач.-балк. – карачай-балкар.
Ком. – комык.
Кырг. – кыргыз.
Тат. – татар.
Төр. – төрек.
Үзб. – үзбәк.

***Хәбибуллина Лениза Газинур кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*